**КАРАР**
**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Актүбә шәһәр тибындагы бистәсе Советы**

Актүбә ш.т.б. № 43 «23» ОКТЯБРЬ 2019 ел

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Актүбә шәһәр тибындагы бистә» муниципаль берәмлеге җирле үзидарә органнарында аерым нотариаль гамәлләр кылу буенча дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруда катнашу турында

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Актүбә шәһәр тибындагы бистә» муниципаль берәмлегендә нотариус булмау сәбәпле, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 №131-ФЗ Федераль законның 14.1 статьясындагы 1 өлешенең 3 пункты, 20 статьясындагы 4.1 өлеше, 11.02.1993 ел №4462-1 нотариат турында Россия Федерациясе законнары нигезләренең 1 һәм 37 статьялары нигезендә

**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Актүбә шәһәр тибындагы бистә Советы карар чыгарды:**

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Актүбә шәһәр тибындагы бистә» муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнары аерым нотариаль гамәлләр кылу буенча дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруда катнаша дип билгеләргә.
2. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Актүбә шәһәр тибындагы бистә» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетына аерым нотариаль гамәлләр кылу вәкаләтләрен гамәлгә ашыруны тәэмин итүче чаралар күрергә тәкъдим итәргә.
3. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Актүбә шәһәр тибындагы бистә Советының 22.01.2008 ел №3 «Актүбә шәһәр тибындагы бистә» муниципаль берәмлеге җирле үзидарә органнарында аерым нотариаль гамәлләр кылу буенча дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруда катнашу турында» карары үз көчен югалткан дип танырга.
4. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» түбәндәге веб-адрес буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының Интернет-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында да веб-адрес буенча: http://aznakayevo.tatarstan.ru. урнаштырырга.

Рәис Р.А. Галеева